КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 24 май г.Казань № 632

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Химик көнен бәйрәм итү турында» 2022 ел, 28 февраль, 172 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Химик көнен бәйрәм итү турында» 2022 ел, 28 февраль, 172 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Республика башкарма хакимият органнарына үтәргә, шулай ук Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитетына, «Татнефтехиминвест-холдинг» акционерлык җәмгыятенә, «СИБУР Холдинг» гавами акционерлык җәмгыятенә, «ТАИФ» акционерлык җәмгыятенә, «Түбән Кама нефтехим» гавами акционерлык җәмгыятенә, «Казаньоргсинтез» гавами акционерлык җәмгыятенә, «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә, «Казан милли тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенә, нефть-газ химиясе комплексы предприятиеләренә һәм оешмаларына күрсәтелгән чараларны әзерләүдә һәм үткәрүдә ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында Химик көнен бәйрәм итүгә багышланган тантаналы һәм мәдәни-массакүләм чаралар әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты составында:

оештыру комитеты составыннан А.Л.Ильинны, А.А.Кәримовны, А.П.Савельчевны, А.Ф.Сафинны, Т.Д.Сөләймановны, Д.А. Таюрскийны чыгарырга;

оештыру комитеты составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Коробченко Олег Владимировичны | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарын – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры, оештыру комитеты рәисе урынбасарын |
| Миңнебаев Марат Фәйзрахман улын | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасарын |
| Насыйбуллина Эльза Илдар кызын | Сәнәгатьнең химия тармаклары хезмәткәрләренең Россия һөнәри берлеге иҗтимагый оешмасының Татарстан республика оешмасы рәисен (килешү буенча) |
| Садыйков Ринат Наил улын | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрын |
| Сафин Ленар Ринат улын | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе ректорын (килешү буенча) |
| Фәләхов Марат Инил улын | «Түбән Кама Нефтехим» гавами акционерлык җәмгыятенең җитештерү, операция нәтиҗәлелеге һәм җитештерү системасын үстерү буенча генераль директорның беренче урынбасарын (килешү буенча); |

Галиев Ренат Марат улы вазыйфасының исемен  түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе, оештыру комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча)»;

Муллин Рамил Хәмзә улы  вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Түбән Кама  муниципаль районы башлыгы (килешү буенча)»;

Рафинат Самат улы Яруллинның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татнефтехиминвест-холдинг» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры                                                                 А.В.Песошин